■ Ислам кагыйдәләре

# ТӨШЕМДӘ ӘБИЕМ, НАМАЗ УКЫ, ДИДЕ

**Дилбәр ГАРИФ**
*Казан шәһәре*


“Төшемдә моннан биш ел элек бакый дөньяга күчкән әбиемне күрдем. Ул үзенең яраткан ак яулыгыннан, намаз укыганда кия торган ачык төстәге иркен күлмәгеннән иде. Үзе нәрсәдәндер канәгать булган кебек, шат, елмая. Аякларын сузып, чирәмлектә утырып тора. Мин дә каяндыр килеп чыгып, аның янына чүмәштем. Аны кочып алып: “Әби, теге дөньяда ничек анда, нәрсә эшләргә кирәк?” - дип сорадым. Әбием, бармаган кисәтү рәвешендә селкеп һәм бик җитди итеп, намаз укырга кирәк, кызым, диде”.

Бу төшне миңа танышым Сания апа сөйләгән иде. Төшемдә әбиемне күрдем бит әле, миңа ап-ачык итеп: “Намаз укырга кирәк, дип әйтте”, - диде ул. Сүз ара сүз китеп, Сания апа миңа туганнан туган энесе Рамил күргән төш турында да сөйләде. Әйтүенчә, әлеге туганының каенәнесе бик акыллы, уңган, дини егет булган. Бервакытта да биш вакыт намазын калдырмаган. Шул егет якын туганнары белән машинада Мәскәүгә барганда юл һәлакәтенә очраган. Кардәшләре барысы да исән калган, ә егетне коткарып кала алмаганнар. Каенәнесен җирләгәннән соң, Рамил аны төшендә күргән. Ул: “Рамил, иртәнге намазны булса да укы инде”, - дип кисәткән.

Дустымның да шундыйрак эчтәлектәге төше турында сөйләгәне бар. Алсуның әтисе бик яшьли үлеп киткән. Дәү әнисе аңа: “Кызым, әтиеңне төшемдә күрдем. Ул, монда, әни, адым саен бисмилла дип әйтергә кирәк икән, диде”, - дигән.

Мондый төшләр нәрсәне аңлата, аларны нәрсәгә юрарга кирәк - “Кол Шәриф” мәчетеннән Рөстәм хәзрәт Бакировтан без шундый эчтәлектәге төшләргә аңлатма бирүен сорадык:

- Дин буенча төшләр өч төрле була. Берсе - Аллаһы Тәгаләдән, ул кешеләргә рас мәгълүматлар бирә. Икенчесе - шайтаннан, өченчесе - кеше алҗудан яки саташып күргән төш. Нинди төш күрсәк тә, Аллаһыдан хәерлесен сорарга тиешбез. Намаз укырга кирәклек турындагы төшләргә килгәндә, минем фикеремчә, кеше мәрхүм булгач, аның җаны үзеннән алда үлгәннәрнең җаннары белән очрашып хәбәрләшәдер. Алар, кире кайтырга мөмкинчелек булса, без намаз укыр идек, дип әйтәләрдер. Намазның бигрәк тә иртәнгесе саваплы, дип, якыннарын, туганнарын кисәтәләрдер. Аллаһы Тәгалә “Коръәни-Кәрим”дә әйтә: “Бик күбегез бу тормышта шатланашатлана җир өстендә йөрисез, дингә өндәүчеләр килгәч, сез аларга ышанмыйсыз, ышансагыз да, үтәмисез. Ләкин үлем фәрештәсе килеп җан алган мизгелдә һәрберегез дә, йа Раббым, син миңа бер генә көн бир инде, шушы вакытта мин көне-төне ураза тотып, намаз укып, көнемне гыйбадәттә үткәрер идем, бер Сиңа гына ышаныр идем, дип әйтер иде”. Ләкин Аллаһы Тәгалә әйтә: “Сезгә шундый мөмкинчелек бирсәк, сез барыбер дөньяны куып үтәр идегез”, - ди. Моңа тормыштан мисаллар күп китереп була: кеше



самолетта очканда, әгәр очкыч бераз гына селкетеп алса да, барысы да тәүбәгә килә, Аллаһыны искә төшерә башлый, төрле әманәтләр әйтә. Самолет җиргә исән-имин төшкәч, күбесе, кызганыч, дингә килергә мин әле яшь, вакыты җитмәгән, пенсиягә чыккач, дип, тагын дөнья куып китә. Шулай булмасын өчен, төшкә кергән рухлар, ахирәттә гамәлгыйбадәт кенә кирәк, дөнья да, тормыш та, кием дә, коттедж да кирәк түгел, дип кисәтәдер. Бу төшләрне, Аллаһы кушканны берүк үтә, намазга бас, башлаганда иртәнге намазны булса да укы, дип кисәтү, өндәү кебек кабул итәргә кирәктер.

Мондый төшләр Аллаһыданмы, шайтаннанмы, арудан-алҗуданмы икәнен әйтә алмыйбыз. Нинди төш керсә дә, аны бары тик яхшыга гына юрарга. Аллаһыдан, хәерлесе булсын, дип сорарга кирәк. Шул рухларның күңелләре шат, урыннары җәннәттә булсын, дип, дога кылыгыз. Әлеге төшләрдән барчабыз да гыйбрәт алсак иде.

Безгә күп кешеләр төшемдә намазга өндәгәнне күрдем, үлгән әти-әниемне күрдем, дип килә. Дога өмет итәләрдер инде, дога кылыйк әле, хәзрәт, диләр. Намаз уку кирәклеге турында сөйли башлагач, эшкә ашыгам, вакытым юк, дип, китеп тә баралар. Намаз укудан куркалар, аны, нишләптер, кыенлык итеп күрәләр. Намаз уку бит ул - бәхет. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) шундый хәдисе яки әйткән сүзе бар, намаз уку - җәннәтнең ачкычы инде ул, ди. “Лә иләәһә иллаллаһ Мөхәммәд рәсүлүллаһ” дип әйтербез, җәннәткә дә барып җитәрбез, әмма аның ишеге бикле булыр, ди. Өй ишеге бикле булгач, без, кесәдән ачкычны алып, ачып керәбез бит, Пәйгамбәребез дә, шуның кебек җәннәткә килеп җитәсез, җәннәт ишеге бикле була, кесәгездән ачкычны алыгыз да ачып керегез, ди. Ә ачкычның исеме - намаз. Намаз укысак, кесәдә ачкыч булган шикелле, җәннәткә керергә өмет бар, ә ачкычсыз нинди генә ишеккә килсәң дә, кереп булмый.

Машинаны кабызыр өчен дә, йортка кайтсак та ачкыч кирәк булган кебек, җәннәткә дә ачкыч кирәк. Кайберәүләр, хәзрәт, без намаз укыр идек, әмма пенсиягә чыккач, ди. Машина алыгыз да пенсиягә чыккач йөрегез, йорт сатып алыгыз да, анда пенсиягә чыккач кына яши башларсыз, дим. Берсе дә ризалашмый.

Машинада бүген йөрисем килә, фатирда бүген яшисем килә, диләр. Җәннәткә керүне дә пенсиягә чыккачка калдырыйкмы? Бу берничек тә мантыйкка сыя торган хәл түгел. Иделдә күптән түгел генә теплоход батты. Андагыларның күбесе яшьләр булган. Беркем дә кайчан гомере тәмамланасын белми.

Беребезгә дә пенсиягә чыгасың да намаз укыйсың, дигән гарантия юк. Шуңа да намаз укуны пенсиягә чыккачка калдырып, соңламасак иде.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Шәүүәл 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Шәүүәл | Аҙна көндәре | Август, сентябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шишәмбе | 30 | 5.50 | 7.20 | 14.30 | 19.42 | 21.12 | 22.42 |
| 2 | Шаршамбы | 31 | 5.52 | 7.22 | 14.30 | 19.40 | 21.10 | 22.40 |
| 3 | Кесе йома | 1 | 5.53 | 7.23 | 14.30 | 19.37 | 21.07 | 22.37 |
| 4 | Йома | 2 | 5.55 | 7.25 | 14.30 | 19.35 | 21.05 | 22.35 |
| 5 | Шәмбе | 3 | 5.57 | 7.27 | 14.30 | 19.32 | 21.02 | 22.32 |
| 6 | Йәкшәмбе | 4 | 5.59 | 7.29 | 14.30 | 19.30 | 21.00 | 22.30 |
| 7 | Дүшәмбе | 5 | 6.01 | 7.31 | 14.30 | 19.27 | 20.57 | 22.27 |
| 8 | Шишәмбе | 6 | 6.03 | 7.33 | 14.30 | 19.25 | 20.55 | 22.25 |
| 9 | Шаршамбы | 7 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.22 | 20.52 | 22.22 |
| 10 | Кесе йома | 8 | 6.06 | 7.36 | 14.30 | 19.20 | 20.50 | 22.20 |
| 11 | Йома | 9 | 6.08 | 7.38 | 14.30 | 19.17 | 20.47 | 22.17 |
| 12 | Шәмбе | 10 | 6.10 | 7.40 | 14.30 | 19.15 | 20.45 | 22.15 |
| 13 | Йәкшәмбе | 11 | 6.12 | 7.42 | 14.30 | 19.12 | 20.42 | 22.12 |
| 14 | Дүшәмбе | 12 | 6.14 | 7.44 | 14.30 | 19.10 | 20.40 | 22.10 |
| 15 | Шишәмбе | 13 | 6.15 | 7.45 | 14.30 | 19.07 | 20.37 | 22.07 |
| 16 | Шаршамбы | 14 | 6.17 | 7.47 | 14.30 | 19.05 | 20.35 | 22.05 |
| 17 | Кесе йома | 15 | 6.19 | 7.49 | 14.30 | 19.02 | 20.32 | 22.02 |
| 18 | Йома | 16 | 6.21 | 7.51 | 14.30 | 19.00 | 20.30 | 22.00 |
| 19 | Шәмбе | 17 | 6.23 | 7.53 | 14.30 | 18.57 | 20.27 | 21.57 |
| 20 | Йәкшәмбе | 18 | 6.25 | 7.55 | 14.30 | 18.54 | 20.24 | 21.54 |
| 21 | Дүшәмбе | 19 | 6.27 | 7.57 | 14.30 | 18.52 | 20.22 | 21.52 |
| 22 | Шишәмбе | 20 | 6.28 | 7.58 | 14.30 | 18.49 | 20.19 | 21.49 |
| 23 | Шаршамбы | 21 | 6.30 | 8.00 | 14.30 | 18.47 | 20.17 | 21.47 |
| 24 | Кесе йома | 22 | 6.32 | 8.02 | 14.30 | 18.44 | 20.14 | 21.44 |
| 25 | Йома | 23 | 6.34 | 8.04 | 14.30 | 18.42 | 20.12 | 21.42 |
| 26 | Шәмбе | 24 | 6.36 | 8.06 | 14.30 | 18.39 | 20.09 | 21.39 |
| 27 | Йәкшәмбе | 25 | 6.38 | 8.08 | 14.30 | 18.37 | 20.07 | 21.37 |
| 28 | Дүшәмбе | 26 | 6.39 | 8.09 | 14.30 | 18.34 | 20.04 | 21.34 |
| 29 | Шишәмбе | 27 | 6.41 | 8.11 | 14.30 | 18.32 | 20.02 | 21.32 |

# Мөселманның белеме

**Касыйм ОРОЗБАЕВ**

Рамазан айларының берсендә мин очраклы рәвештә бер ямьсез күренешкә тап булдым. Зур бер мәчеткә тәравих намазына барган идем. Бу мәчетнең имамы - бик тә белемле кеше, шактый гына кибетләр аның Ислам дисенең гүзәллеге турындагы лекцияләре язылган компакт-дисклары белән сәүдә итә. Һәрбер тәравих намазында да әлеге имам Коръән аятьләрен елап җибәрердәй булып укыды. Әмма көннәрнең берендә ул, тәравих намазыннан соң мәчеттән чыкканда, куркып калган мөселманнарга ачуыннан бүртенеп кычкыра башлады. Баксаң, кемдер үзенең машинасын нәкъ ишек каршына китереп куйган икән...

### БУШ БЕЛЕМ

Бүгенге көндә Ислам дөньясы белем юклыгыннан зарлана алмый. Барлык гарәп илләрендә һәм Ислам дөньясына керүче башка бөтен илләрдә дә диярлек дистәләрчә һәм йөзләрчә дини уку йортлары, йөзләгән һәм меңләгән галимнәр, күп санлы мәчет-мәдрәсә, китапханәләр, сайтлар эшләп тора.

Бүген, өеңнән чыкмаган килеш тә, компьютер клавиатурасы артына утырып, дини вазифаларны тиешенчә үтәргә өйрәтүче Ислам белеменә ия булырга мөмкин. Бу белем хәтта кешеләрне Исламга өндәү һәм Аллаһы дине турында чагыштырмача тулы мәгълүмат бирергә дә җитә.

Дини вузлар ел саен Исламга өндәү, фикъх, мөселман тарихы һәм икътисады өлкәсендә меңнәрчә белгеч әзерләп чыгара. Ислам дөньясында ел саен меңләгән магистрлык эшләре һәм докторлык диссертацияләре яклана, яңа Ислам китапларын бастыру өчен тонналаган кәгазь тотыла, хөтбәләр һәм вәгазьләр язылган меңәрләгән кассета һәм лазер дисклары чыгарыла.

Әмма ни өчендер инде дистә еллар дәвамында бу белемнәр өммәткә сизелерлек файда китерә алмый. Мәчет ишеген атлап чыгуга, мөселманнар тыңлаган вәгазьләре турында онытalar. Урамдагы халык ташкынына килеп кушылгач, укыган китапларын исләренә төшерә алмыйлар.

Ислам белеме бу заманда ни сәбәпле шулай нәтиҗәсез икән соң? Эш шунда, лазер дискларына, китапларга язылган, хөтбәләрдә сөйләнгән бу белем - теоретик белем генә, ул мөселманнарның конкрет эшләре белән ныгытылмаган.

Беркемгә дә сер түгел, Ислам вәгазьчеләре, имамнары һәм галимнәре күп очракта камил әхлак үрнәге булып тормый... Һәм биш-алты ел буе Ислам вузларында укып чыккан студентларның да туган якларында Исламга өндәүне ничек башлап китәргә белмәүләре берәүгә дә сер түгел.

### ТОРМЫШКА АШКАН БЕЛЕМ

Әмма Исламның шактый гына дип галимнәре, вәгазьчеләре һәм студентлары онытып җибәргән бер үзенчәлеге бар. Ул - лекцияләр һәм тапшырылган имтиханнар дине түгел. Ул - конкрет эшләр һәм гамәлләр дине. Ул - алган белемнәреңне тормышка ашыру дине. Мөнбәрләрдән Ислам кардәшлеге турында сөйләп тә, үзләре бер генә мөселман белән дә чын туганнарча мөнәсәбәттә тормаган меңнәрчә галимнәр һәм имамнардан ни мәгънә? Нәкъ менә шундыйларның берсе - студентларга көн саен Ислам турында лекцияләр укучы галим - дәресләрдән соң бер студентка, тулай торак өчен түләүне бер генә көнгә кичектерсә дә, урамга куып чыгару белән яный. Ислам институтлары ел саен меңнәрчә Коръән-хафиз укытып чыгарса да, хафизлар Коръәннең бер генә аятен дә тормышка ашырмаса, андый институтлардан ни мәгънә? Коръәнне - ике елда! Ә бит хәтта Пәйгамбәрнең (салаллаһу галәйһи вәссәләм) сәхабәләре берьюлы ун аятьтән артык өйрәнмәгән. Өйрәнгәннәренең мәгънәсен аңлап, үз тормышларына тулысынча керткәннән соң гына башкаларына тотынганнар.

Ислам белеме нәкъ шул рәвешчә - ашыкмыйча, төпле һәм ышанычлы итеп өйрәнелергә тиеш. Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында бу хакта болай ди: “Коръәнне аять төшендереп иңдердек кешеләргә һәр аятьне аңлатып укымаклыгың өчен вә ул Коръәнне кешеләрнең гакыл фикерләренә һәм көчләренә карата иңдердек”.

Димәк, Ислам белемен алу һәм үзләштерү - Коръәнне һәм сөннәтне теоретик яктан өйрәнү генә түгел. Ул - кеше үзе өйрәнгән һәр аятьне һәм хәдисне турыдан-туры тормышка ашыру дигән сүз. Иртәгә, ярты елдан соң, пенсиягә чыккач түгел, ә нәкъ менә бүген һәм хәзер.